ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИСАНСУПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНАРЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСӘНСЕФ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423988, РТ Муслюмовский район д. Татарское Булярово. ул. Молодежная, д. 12
ИНН/КПП—1629003897/162901001 ОГРН – 1061687001221

Татар Бүләр авылы **КАРАР № 17** «27 сентябрь 2021 ел.

**«Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 июлендәге 13 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында:**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 июлендәге 13 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән расланган Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 – 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта федераль мәгълүмат адреслы системасының дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм эксплуатацияләүгә бәйле кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмати адреслы система турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 28 декабрендәге Федераль законга, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карары нигезендә төгәл берлектә кулланыла».»;

1.2. 1.5. пунктының 11 – 17 абзацларын 3 – 9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4 – 7 пунктчаларындагы «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «Башкарма комитет яисә төзелгән килешү нигезендә муниципаль район җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4 пунктындагы «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе тарафыннан» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** Сахбутдинова Ф.Т.